ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-РӘҖӘП АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

22.09.2020 №4

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 сентябрендәге 56-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы "Иске-Рәҗәп авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (14.09.2016 № 20-2, 06.12.2018 № 57-1, 23.04.2019 №64-1, 13.09.2019 № 96-1, 13.09.2019 № 72-1, 24.01.2020 №83-2 үзгәрешләр белән)

2020 елның 13 июлендәге N 202-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 сентябрендәге 56-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы "Иске-Рәҗәп авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (14.09.2016 № 20-2, 06.12.2018 № 57-1, 23.04.2019 №64-1, 13.09.2019 № 96-1, 13.09.2019 № 72-1, 24.01.2020 №83-2 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 29 статьясындагы 5 пунктының дүртенче абзацында ", РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объектының мәйданы үзгәрү очракларыннан тыш, ";

1.2. Кагыйдәләрнең 29 статьясындагы 5 пунктындагы бишенче абзацында «проект документациясе» сүзләреннән соң «РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Иске-Рәҗәп авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев